**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 19 октябрь

№ 762

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2006 ел, 7 июнь, 275 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 16 февраль, 47 нче; 2007 ел, 14 июнь, 235 нче; 2008 ел, 26 ноябрь, 832 нче; 2009 ел, 27 февраль, 115 нче; 2009 ел, 8 апрель, 209 нчы; 2009 ел, 21 август, 571 нче; 2010 ел, 2 апрель, 229 нчы; 2015 ел, 4 февраль, 61 нче; 2015 ел, 12 март, 146 нчы; 2016 ел, 13 май, 305 нче; 2016 ел, 26 май, 359 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Федераль бюджеттан бүлеп бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гражданнарның аерым категорияләренә торак сатып алу өчен субсидияләр бирү турындагы нигезләмәдә:

8 пунктның өченче абзацында «әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ветераннар, инвалидлар, инвалид балалар арасыннан затны (субсидия алучыны) гомуми мәйданы 18 кв.метрдан ким булмаган торак белән тәэмин итә торган милек хокукы теркәлгән торак урынын сату-алу шартнамәсе яисә күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган органда теркәлгән бүтән шартнамә, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны үткәрүне раслый торган Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәне теркәп.»;

дүртенче абзацта «әлеге шартнамә шартларын тормышка ашыру нәтиҗәсендә алынган, акчаны алучы исеменә яисә акчаны алучы һәм аның гаилә әгъзалары исеменә рәсмиләштерелгән аңарга милке хокукын дәүләт теркәвенә алу турында

таныклык» сүзләрен «хокукларны дәүләт теркәвенә алуны үткәрүне таныклый торган Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә»;

әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтада «Территориаль социаль яклау органы җитәкчесе» сүзләрен «Муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар, террор актлары аркасында яисә хокукый гамәлләр белән террор актларын туктатканда торак урынсыз калган Россия Федерациясе гражданнарына бирелгән дәүләт торак сертификатларын гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 11 июль, 488 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 декабрь, 1067 нче, 2014 ел, 19 август, 600 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар, террор актлары аркасында яисә хокукый гамәлләр белән террор актларын туктатканда торак урынсыз калган Россия Федерациясе гражданнарына бирелгән дәүләт торак сертификатларын гамәлгә ашыру тәртибенең 12 пунктындагы бишенче абзацта «бирелгән, хокукны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык» сүзләрен «бирелгән, хокукларны дәүләт теркәвенә алуны үткәрүне таныклый торган Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә» сүзләренә алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» 2016 ел, 18 апрель, 236 нчы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбенннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең 6 пунктында «милек хокукын теркәүгә алу турында таныклык» сүзләрен «хокукларны дәүләт теркәвенә алуны үткәрүне таныклый торган Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр» сүзләренә алмаштырырга.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру турында» 2016 ел, 9 август, 549 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итү буенча пилот проектын тормышка ашыру белән

бәйле хезмәтләр күрсәтүгә юридик затларның чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

2.3 пунктның бишенче абзацында «милек хокукын теркәүгә алу турында таныклык» сүзләрен «хокукларны дәүләт теркәвенә алуны үткәрүне таныклый торган Күчемсез мөлкәткә хокукларны һәм аның белән алыш-бирешләрне теркәүнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләр» сүзләренә алмаштырырга;

3.5 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган 2016 елда Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итүне оештыру тәртибе нигезендә Татарстан Республикасының социаль яклау, социаль хезмәт күрсәтү, халыкны эш белән тәэмин итү, яшьләр эшләре һәм спорт буенча дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләрен шифаханә-курорт дәвалануы белән тәэмин итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә субсидия зурлыгы, аның максатчан билгеләнеше, чыгымнар төрләре, субсидияне күчерү тәртибе һәм вакытлары (шул исәптән финанслар белән тәэмин итү чыганагы субсидияләрнең хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеге (мөмкин булмау), Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән очраклардан тыш, алынган субсидия исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, шифаханә-курорт дәвалануына юллама бүлеп бирүгә гариза кабул итү пунктлары (урыннары) турында хезмәткәрләргә мәгълүмат бирү тәртибе, субсидияне файдалану турында хисап бирү тәртибе һәм вакытлары, субсидияләрнең хисап финанс елында файдаланылмаган өлешләрен субсидия алучы тарафыннан агымдагы финанс елында кире кайтару очраклары, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын, тәртибен үтәвен тикшерүләр оештыруга субсидия алучы ризалыгы (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләр, устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый оешмалар катнашуда хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый иптәшлекләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерциячел оешмалардан тыш), субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәү турында нигезләмәләр күздә тотыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\762.docx